Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

# КАРАР

27 февраль 2023 ел. №3

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 нчы номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 нчы номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 30 нчы номерлы, 2019 елның 16 маендагы 8 нче номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 11 нче номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 4нче номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 14 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчаны өстәргә:

«12) алар тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;

1) 15 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Нәбиев И.М.